Республика Татарстан
Глава Тураевского
сельского поселения
Менделеевского
муниципального района
423647, село Тураево,
ул. Центральная. 11А

Татарстан Республикасы
Менделеев
муниципаль районы
Турай авыл жирлеге
башкарма комитеты
423647, Турай авылы,
Узәк урам, 11А

Тел./факс 2-73-31

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

01.11.2025 № 11

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Татар Әхтиялы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлеге Уставының 22 ст. нигезендә
КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 елның 13 ноябре 16.00 сәг. Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Татар Әхтиялы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә. Җыен уздыру урыны итеп Татар Әхтиялы авылы, Үзәк урам, 9Б йорт адресы буенча урнашкан Татар Әхтиялы авылының иҗтимагый үзәк бинасын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенында түбәндәге сорауны расларга:

“2026 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Тататар Әхтиялы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә билгеләргә. 1 төркем инвалидларны һәм махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә

әгъзаларын түләүдән азат  итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә Сез ризамы?”:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Татар Әхтиялы торак пункты урамнарының юл өслеген вак таш белән чокырларны ремонтлау; Татар Әхтиялы торак пунктында вак таштан соң юл өслеген тигезләү ( эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (кышкы чорда юлларны кардан чистарту (шартнамә буенча эшләр өчен түләү)

3) урамнарның тышкы яктырту челтәрләрен ремонтлау (яктырткычлар сатып алу)

4) җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (чишмәне кору)

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru  һәм www Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http:///mendsleevsk.tatarstan.ru  “Турай авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы  Менделеевск
муниципаль районы Турай
авыл җирлеге башлыгы А.Т. Нуриев